Тема: **Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре, аларның белдерелүе**

Сыйныф: **9**

Фән: **туган тел**

- ***Бирем.*** Җөмләләрне дөрес интонация белән укырга, төрен әйтергә.

Сүзләр, мин сезне ничек яратам! Мин Сезгә бурычлы. Сез мине үз кадерегезне дә, тормыш кадерен дә аңларга өйрәттегез. Ә сез сүзләрне яратасызмы?

- *1.Кояш елмая. Тамчылар тама. Карлар эри. Сулар сеңә.*
- *2. Күктә язгы кояш елмая. Түбәләрдән тамчылар тама. Кояш җылысына карлар эри. Сулар әкренләп җир куенына сеңә.*
- - Бу текстлар нәрсә белән охшаш? (Төп эчтәлек белән)
- - Нәрсә белән аерылалар? ( Икенче текстта язгы көн турында тулырак, төгәлрәк бирелгән.)
- - Ни өчен икенче текст тулырак, төгәлрәк? (Анда иярчен кисәкләр дә бар.)

# Җөмлә кисәкләре

**ҖӨМЛӘ КИСӘКЛӘРЕ**

- баш кисәкләр
  - ия
  - хәбәр
- иярчен кисәкләр
  - аергыч
  - тәмамлык
  - хәл
  - аныклагыч
- модаль кисәкләр
  - эндәш сүз
  - кереш сүз



***Алсу, син кызыл алмаларны тартмага, ягъни яшел савытларга, зинһар, җый.***

син → җый → кызыл → алмаларны → тартмага → яшел савытларга → Алсу → зинһар

Активация Windows
Чтобы активировать Windows, перейдите в раздел "Параметры".

**Татар телендә җөмлә кисәкләре зур өч төркемгә аерыла: баш, иярчен һәм модаль кисәкләр.**

# Ия




Җөмләнең башка сүзгә буйсынмаган баш кисәге **ия** дип атала. Иянең төп үзенчәлекләре:





1. Ия һәрвакыт **баш килештә** килә:

*<u>Мәктәп</u> зур.*

2. Иягә ***-ны/-не*** һәм ***-ның/-нең*** кушымчаларын куеп карап булмый:

*Мин ~~күлмәк~~ (-не) юдым. Мин ~~әни~~ (-нең) күлмәген юдым.*

3. Ия янында **бәйлек** һәм **бәйлек сүзләр** килми:

*Мин театрга ~~әни~~ белән барам.*

Активация Windows
Чтобы активировать Windows, перейдите в раздел "Параметры".

# Иянең төрле сүз төркемнәре белән белдерелүе




**ия**

| | |
|---|---|
| исем | *__Алмаз__ мәктәпкә китте.* |
| алмашлык | *__Ул__ 8 нче сыйныфта укый.* |
| исемләшкән сыйфат | *__Кызыл__ – матур төс.* |
| исемләшкән рәвеш | *Безнең сыйныфта __күпләр__ спорт түгәрәгенә йөри.* |
| исемләшкән сан | *Биремне __икебез__ тактага язып эшлибез.* |
| исемләшкән фигыль | *__Укыган__ күп белә.* |













**Ия баш килештәге исемнәр, алмашлыклар һәм исемләшкән сүз төркемнәре белән белдерелә.**

Активация Windows
Чтобы активировать Windows, перейдите в раздел "Параметры".

# Иянең төзелеше ягыннан төрләре

ИЯ

## гади

*<u>Алсу</u> мәктәптә укый.*

*Сары <u>яфраклар</u> оча.*



## тезмә

*Безне <u>Алсу Хәмитовна</u> укыта.*

*<u>Үги ана яфрагы</u> үсә.*



**Ия төзелеше ягыннан ике төрле: гади һәм тезмә була.**

Активация Windows
Чтобы активировать Windows, перейдите в раздел "Параметры".

# Хәбәр

**Җөмләнең ия турында хәбәр итә һәм аңа иярeп килә торган баш кисәге хәбәр дип атала.**



*Марат җир казый.*
*Лилия кишер җыя.*
*Айсылу кәбестәләрне капчыкка сала.*
*Әтиләре карлыган куакларын бәйли.*



Активация Windows
Чтобы активировать Windows, перейдите в раздел "Параметры".

# Хәбәрнең төрләре

**ХӘБӘР**

**исем хәбәр**

исем, алмашлык, сан, сыйфат, рәвеш, исем фигыль, аваз ияртеме, хәбәрлек сүз




*Мин — укучы.*

*Күлмәк матур.*

*Көндәлегем юк.*

**фигыль хәбәр**

фигыль



*Көз җитте. Укучылар мәктәптә укый башладылар.*

**Хәбәрләр төрле сүз төркемнәре белән белдерелә ала. Кайсы сүз төркеме белән белдерелүенә карап, алар ике зур төркемгә бүленәләр. Фигыль сүз төркеме белән белдерелсә, ул — фигыль хәбәр, калган сүз төркемнәре белән белдерелсә, исем хәбәр дип атала.**

Активация Windows
Чтобы активировать Windows, перейдите в раздел "Параметры".

Дәреслектәге 44 нче күнегү (43 нче бит)

Бирем. Җөмләләрне җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерергә.

Биремне үтәргә.

Сораулар урынына, мәгънә ягыннан туры килерлек иярчен кисәкләр куеп, җөмләләрне яз. Иярчен кисәкләр кайсы сүзгә бәйләнгәнен уклар белән күрсәт.

1. *Җил (нәрсәләрне?) сындырды.*
2. *Куян (кемнән?) курыкты.*
3. *Песнәк (нәрсәдән?) (нәрсәгә?) сикереп, (нәрсәләрне?) чүпли.*
4. *Җил (нәрсәләрне?) очырта.*
5. *(нинди?) күктә әкрен генә (нинди?) болытлар йөзәләр.*

**Өй эше**

Өзекне күчерегез, баш һәм иярчен кисәкләрнең асларына сызыгыз, нинди сүз төркемнәре белән белдерелүен языгыз.

Гүзәл китаплар - гаҗәеп эшләрне күрсәтүче көзге. Алар аулакта сердәш, ялгызлыкта иптәш, кайгылы ва зиһенгә куәт кертер.

Китап уку кешенең йөзенә нур, күңеленә шатлык китерер, шуның өчен акыл хезмәте белән шөгыльләнүчеләрнең йөзләре мәхәббәтле булыр.